СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2022 елның «12» августы Алабуга шәһәре № 187

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2014 елның 12 ноябрендә кабул ителгән 462 номерлы "Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, чыгымнары , мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында"гы карарына үзгәрешләр кертү турында

2012 елның 3 декабрендә кабул ителгән 230-ФЗ номерлы "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында"гы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы карары белән расланган Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында 2014 елның 12 ноябрендә кабул ителгән 462 нче номерлы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 6 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"в) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар, цифрлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларынын чыгымнары турында мәгълүматлар (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), әгәр килешү суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш кылуга алдагы өч елда һәм алыш-биреш кылынган акчалар алу чыганаклары турында белешмәләр.".

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Новая Кама» газетасында, «Алабуга Нуры» газетасында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук городелабуга.рф рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль төзелеш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Рәис урынбасары О. Е. Колпаков